

Россиянен vткән һәм хәзерге батырлыгын, рухи кыйммәтләрен саклап калу очен Рузаевка районы Татар Пешлә урта гомуми белем бирv мәктәбендә ел саен 3-9нчы декабрь коненә  кадәр Ватан Батырлары коненә багышлап, класстан тыш кичәләр vткәрелә.
Шулай, 9нчы декабрь конне 10нчы сыйныфта бәйрәмнен тарихы, халыкнын батырлыгы турында класс житәкчесе белән укучылары сойләде. Батырлык һәм намуслык темасына әнгәмә vткәрдек. Укучылар шигырьләр сойләде («Россия», «Сугыш ордены белән бvләкләнә...»), жырлар жырланды («Синен очен Ватан-Ана»), Боек полководецлар турында докладлар ясалды (М.И.Кутузов белән М.Б.Барклай-де-Толли), «Ватан Батырлары: vткәннәре һәм хәзергеләре»  темасыны презентацияләр кvрсәтелде, Георгий тасмасы тарихы турында да искә алдык.      Георгий тасмасы – ул мәнгелек гасырлар символы, сугыш кырларында сугышчыларнын батырлыгын жанландыру, дигән сvз. Бер бvләк элементы очен vз жаннарын да кызганмаганнар.
Аннан сон Боек Ватан сугышында һәлак булган авылдашлар һәйкәле янынына чәчәкләр куярга юл тоттык.Укучылар һәйкәлгә чәчәкләр куйганнан сон, бер минут телгә килмичә тордык һәм һәйкәл янын кардан чистарттык. Шундый кvнелле vтте бу кон! Актив катнашкан укучыларымны әйтми булдыра алмыйм. Алар: Бадамшин Адель, Ларина Альбина, Люртяева Амина, Кузиков Ильдар, Нарваткин Петр. Олы һәм кече Ватаннарын яратып vсә алар.

**Сания Саляева**